Татарстан Республикасы
Әлмәтмуниципаль районы
Аппак авыл Советы

# КАРАРЫ

12 май 2020 ел № 108

Татарстан Республикасы Әлмәтмуниципаль районы Аппак авыл Советының 2018 елның 27 ноябрендәге 77 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл башкарма комитеты турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Аппак авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл Советының 2018 елның 27 ноябрендәге 77 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Аппак авыл башкарма комитеты турында нигезләмә хакында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче бүлектә:

1.1.1. 1.5.пунктында «җирлек башлыгының карарлары һәм күрсәтмәләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.1.2 1.12 пунктында «Штат расписаниесе» сүзләрен «Структура» сүзенәалмаштырырга;

1. 2. 4 бүлекнең 4.1. пунктында:

1.2.1. 4)нче пунктчаны төшереп калдырырга;

1.2.2. 5) нче пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүдә ярдәм итәргә, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудырырга;»

1.3. 4.2 пунктының уналтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә, үз белдеге белән төзелгән корылманы күчерү, үз белдеге белән корылманы сүтү яки капиталь төзелеш объектларын, реконструкцияләүнең җир белән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары төзүнең рөхсәт ителгән параметрларына туры китерү турында карар кабул итү.»

1.4. 5 бүлекнең 5.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Җирлекнең Башкарма комитеты җитәкчесе үз вәкаләтләре чикләрендә федераль законнарда, Россия Федерациясе субъектлары законнарында, җирлек Уставында, җирлек Советының норматив хокукый актларында билгеләнгән үз вәкаләтләре чикләрендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча һәм җирле үзидарә органнарына федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча җирлек Советы Башкарма комитеты карарларын,

шулай ук җирлек Башкарма комитетының эшен оештыру мәсьәләләре буенча күрсәтмәләрен чыгара.»

2. Әлеге карарны Әлмәт районы, Аппак авылы, Мира урамы, 71; Ильтень-Бута авылы, Советская урамы, 71 йорт территоиясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты “Интернет” челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Аппак авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Аппак
авыл җирлеге башлыгы В.Н. Горбунова